РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Кармалинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423598, Нижнекамский район,
с. Кармалы,ул. Пионерская,1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл жирлеге
Советы

423598, Түбән Кама районы,
Кармалы авылы,Пионер урамы, 1

тел./факс (8555) 33-39-17, электронный адрес: Karmalinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.karmalinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.08.2022 ел № 14

Кармалы авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендә кабул ителгән 30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 45.1 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Кармалы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Кармалы авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендә кабул ителгән 30 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 статьяны түбәндәге эчтәлекле 2.30, 2.31 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.30. Авыл хуҗалыгы хайваннары - терлекчелек һәм башка авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү өчен кулланыла торган терлекләр, кыйммәтле мехлы җәнлекләр, йорт куяннары, кош-корт, умарта кортлары.

2.31. Йорт биләү - торак йорт (торак йортның бер өлеше) һәм аның янәшәсендәге һәм (яисә) торак йорт (торак йортның бер өлеше) белән гомуми җир кишәрлегендә аерым торучы ишегалды корылмалары (гараж, мунча (сауна, бассейн), теплица (кышкы бакча), авыл хуҗалыгы хайваннарын тоту өчен урыннар, башка объектлар).».

1.2. 5 статьяның 7 пунктында «автомобиль юллары милекчеләре тарафыннан» сүзләреннән соң «, җир кишәрлекләре милекчеләре яисә җир кишәрлекләре территорияләре беркетелгән затлар тарафыннан» сүзләрен өстәргә.

1.3. 3 бүлекнең 15 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 статья. Шәхси торак йортларны, шул исәптән сезонлы һәм вакытлыча яшәү өчен файдаланыла торган йортларны карап тоту һәм территорияне төзекләндерү.

Йорт биләү милекчеләре, шул исәптән сезонлы һәм вакытлыча яшәү өчен файдаланыла торган, шулай ук йортта фактта яшәүче затлар, бурычлы:

1) торак йорт фасадларының, киртәләрнең (коймаларның), шулай ук йорт чикләрендәге башка каралтыларның һәм корылмаларның тиешле торышын тәэмин итәргә, үз вакытында аларны тәртиптә тота торган ремонт ясарга кирәк;

2) торак йортта номер билгесе булдырырга һәм аны төзек хәлдә тотарга;

3) йорт яны территориясен тәртиптә тотарга һәм территориянең тиешле санитар торышын тәэмин итәргә;

4) су агып китсен өчен канаулар һәм торбаларны чистартырга, язгы чорда кар суы агу юлын тәэмин итәргә;

5) йорт яны территориясеннән чистартылган карны бер урынга җыйганда, транспорт үтү, инженерлык коммуникацияләренә һәм алардагы корылмаларга керү, җәяүлеләр узу мөмкинлеген һәм яшел утыртмалар сакланышынтәэмин итәргә;

6) сүтелгән (төзек булмаган) транспорт чарасынйорт яны территориясеннән тыш саклауга юл куймаска;

7) автомобильләрне ремонтлау яки юу, май яки техник сыеклыклар алмаштыруны йорт яны территориясеннән тыш башкаруга юл куймаска;

8) җир һәм төзелеш эшләре башкарганда, юлның машиналар йөрү өлешен капламаска;

9) инженерлык коммуникацияләре коеларын һәм яңгыр сулары траншеяларын чүпләмәскә;

10) җирлекнең җирле үзидарә органнары белән төзелеш материалларын һәм эшләнмәләрне йорт территориясе читендә урнаштыру срогын килештерергә.».

1.4. 3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 17.1 статья өстәргә:

«17.1 статья Авыл хуҗалыгы хайваннарын карап тоту

1. Авыл хуҗалыгы хайваннары белән эш итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләр «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, шулай ук алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасының законнары һәм башка норматив хокукый актлары, әлеге Кагыйдәләр белән җайга салына.

2. Йорт хайваннарын тотканда аларның хуҗаларына хайваннарны карап тотуга карата гомуми таләпләрне, шулай ук тирә-юньдәге затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә кирәк. Авыл хуҗалыгы хайваннары китергән зыян өчен аларның хуҗалары Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

3. Авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан авыл хуҗалыгы хайваннарын тоту милек хокукында алар карамагындагы территория чикләрендә яки йорт яны кишәрлекләре белән йорт биләүгә әйбергә иялек хокукында рөхсәт ителә.

Терлек азыгын, тиресне һәм компостны бер урынга җыю авыл хуҗалыгы хайваннары хуҗаларына янгынга каршы, санитар һәм ветеринария таләпләрен мәҗбүри үтәү белән йорт яны кишәрлеге территориясендә генә рөхсәт ителә.

4. Җирлектә авыл хуҗалыгы хайваннарын йорт һәм йорт яны кишәрлеге

чикләреннән тыш көтүлектә йөртү, торак пункттан читтә, җаваплы зат (көтүче) күзәтүе астында,бары тик шушы максатларда билгеләнгән урыннарда гына алып барыла. Торак пункт территориясендә һәм аннан читтә авыл хуҗалыгы хайваннарын контрольсез көтүлектә йөртү тыела. Газоннарда, скверларда, паркларда, балалар өчен уен һәм спорт мәйданчыкларында авыл хуҗалыгы хайваннарын көтүлектә йөртергә ярамый.

Авыл хуҗалыгы хайваннары чәчүлекләрне, кибәннәрне, авыл хуҗалыгы культуралары уңышын, яшел утыртмаларны бозган һәм/яки юк иткән өчен авыл хуҗалыгы хайваннары хуҗалары административ җаваплылыкка тартыла.

5. Авыл хуҗалыгы хайваннарын,мөмкин кадәр юлның уң ягына якынрак юнәлтеп, юллар буйлап бер урыннан икенчесенә күчерү бары тик тәүлекнең якты вакытында гына рөхсәт ителә. Таш түшәлмәгән юллар һәм сукмаклар аша куып алып бару мөмкинлеге булганда, аларны асфальт өслекле юлдан алып бару тыела.

6. Авыл хуҗалыгы хайваннарын балконнарда, лоджияләрдә, күпфатирлы торак йортларның гомуми кулланылыштагы урыннарында (чиктәш фатирларның коридорларында, баскыч урнашкан җирдә, чарлакларда, подвалларда һәм башка ярдәмче урыннарда) даими тоту рөхсәт ителми.

7. Суда йөзүче кошларны ачык һавада йөртү табигый сулыкларда яки йорт яны кишәрлеге чикләрендә ясалма төзелгән буаларда йөртү рөхсәт ителә. Йорт яны кишәрлегеннән читтә ясалма буалар, киртә абзарлар булдыру тыела.

8. Суда йөзүче кошларны табигый сулыкларга кадәр куып алып бару һәм кире алып кайту аның хуҗасы яки хуҗа билгеләгән җаваплы зат күзәтүе астында гамәлгә ашырыла.».

А.Д. Кубышкин